ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл жирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

Карар № 96

“05 “июнь 2024 ел Олы Мәңгәр авылы

Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 113 номерлы карары белән расланган “Олы Мәңгәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында", 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдән туктатылуы һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында", 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон "Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2023 елның 04 декабрендәге 118-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы "Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында” нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге № 113 (№127 10.02.2020 ел, № 134 28.05.2020 ел, № 7 30.10.2020 ел, № 35 06.12.2021 ел, № 48 16.05.2022 ел, № 52 17.08.2022 ел, №82 27.10.2023 ел үзгәрешләр белән) карары белән расланган "Олы Мәңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа абзац белән тулыландырырга:

«- капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасында федераль бюджет акчалары (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (уртак финанслау чыганагы) чыганагы хакында белешмәләр төзи;»;

1.2. 22 статьяның 3 пунктын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән туктатырга;

1.3. 25 статьяның 3 пунктын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән тукататырга;

1.4. 40 статьяның 1 пунктындагы "Башкарма комитет җитәкчесе" сүзләрен "Башкарма комитет" сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 51 статьяның 1 пунктындагы "Башкарма комитет җитәкчесе" сүзләрен "Башлык" сүзе белән алмаштырырга;

1.6. 51 статьяның 3 пунктындагы "Башкарма комитет җитәкчесен" сүзләрен "Башлыклар" сүзе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Филатова Ф.Ф.